РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«5» октябрь 2022г. г. Альметьевск № 82

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының «Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакын түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның 11 маендагы 113 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль берәмлекләр башлыкларын, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларын, депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларын, муниципаль берәмлекләрнең контроль - хисап органнары рәисләрен, Рәис урынбасарларын, аудиторларын айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладлары арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы карары нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының «Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакын түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның 11 маендагы 113 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2020 елның 30 октябрендәге 8 номерлы, 2021 елның 16 декабрендәге 58 номерлы, 2022 елның 20 апрелендәге 67 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарга 1 нче кушымтадагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләме

(сум)

| «Вазыйфаның исеме | Вазыйфаи оклад |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 32 765 |

| | |
|---|---|
| Идарә башлыгы, мөстәкыйль бүлек башлыгы (медире), башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе җитәкчесе | 22 721 |
| Идарә башлыгы урынбасары, мөстәкыйль бүлек башлыгы урынбасары (мөдире), башкарма комитетының башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары | 19 014 |
| Башкарма комитет җитәкчесе ярдәмчесе, башкарма комитет җитәкчесе киңәшчесе | 19 014 |
| Башкарма комитетның идарә составындагы бүлек башлыгы | 19 014 |
| Сектор мөдире | 17 818 |
| Баш белгеч | 17 459 |
| Алып баручы белгеч | 16 383 |
| 1 категорияле белгеч, 2 категорияле белгеч, белгеч | 15 187 |

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле елга җирле бюджетта каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль мәсьәләләр буенча шәһәр Советының даими комиссиясенә йөкләргә (Шәйхетдинова Ф.А.).

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов

•АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ•